**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында матәм игълан итү турында**

Татарстан Республикасының Түбән Кама муниципаль районында производство һәм граждан объектларына пилотсыз очкыч аппаратларның күпләп һөҗүме нәтиҗәсендә һәлак булганнар турында авыр кайгы белдереп, **карар бирәм:**

1. 2026 елның 10 августын Татарстан Республикасында матәм көне дип игълан итәргә.

2. Матәм көнендә Татарстан Республикасының бөтен территориясендә Татарстан Республикасы Дәүләт флагларын түбәнрәк төшерергә.

3. Телерадиокомпанияләргә һәм мәдәният учреждениеләренә матәм көнендә күңел ачу тапшыруларын һәм чараларын үткәрмәүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына фаҗигале вакыйгалар нәтиҗәсендә һәлак булганнарның гаиләләренә һәм зыян күрүчеләргә ярдәм итү буенча тәкъдимнәр әзерләргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 10 август
№ 643